СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның 8 сентябреннән № 26-196

2022 елда «2019-2023 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2023 елга бурычлары турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К.Исхакованың 2022 елда «2019-2023 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2023 елга бурычлары турындамәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда «2019-2023 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын (алга таба - Программаны) гамәлгә ашыруның барышы һәм 2023 елга бурычлары турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:
– 2022 елда Программаны үтәү буенча эшне активлаштырырга;
– муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларына резидентларны җәлеп итү һәм аларга булышу буенча эшне дәвам итәргә, шулай ук аларга сәнәгать мәйданчыклары резидентлары продукциясен эчке һәм тышкы базарларга чыгару өчен маркетинг чараларында ярдәм итәргә;
– эшкуарлык җәмәгатьчелегенә яңа эш башлаучы һәм эшләп килүче эшкуарларга ярдәм итү чаралары турында даими хәбәр итеп торырга;
– Яңа Чишмә муниципаль районының тулаем территориаль продуктында кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өлешен 2022 ел азагына 8,4% ка җиткерергә;
– маркетплейсларда һәм Республика маркетинг үзәгендә эшләү буенча эшмәкәрләр һәм "үзмәшгульләр"белән эшне активлаштырырга;
– кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан сатып алулар өлешен еллык сатып алуларның кимендә 40% дәрәҗәсенә кадәр арттыру буенча өстәмә чаралар күрергә;

– хезмәт базарында квалификацияле эшче көчләр тәкъдим итүне һәм ихтыяҗның туры килүен тәэмин итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

– хезмәт базарында даими мониторинг алып барырга һәм халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өчен чаралар комплексы кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә һәм арендага бирү өчен муниципаль мөлкәт реестрының актуаль торышын тәэмин итүне тәкъдим итәргә;

4. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов